ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясепоселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

_____30.06.2026____________ № 498______

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Бердәм дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча 100 балл алган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларга һәм бердәм дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча 100 балл алган чыгарылыш сыйныф укучыларын әзерләгән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары педагогларына бер мәртәбә түләнә торган түләү билгеләү турында нигезләмәне раслау хакында» 2026 елның 15 апрелендәге 332 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының бердәм дәүләт имтиханы (БДИ) нәтиҗәләре буенча 100 балл алган чыгарылыш укучыларын бүләкләү һәм укытучы һөнәренең абруен күтәрү һәм Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының бердәм дәүләт имтиханында 100 балл алган чыгарылыш сыйныф укучыларын әзерләгән укытучыларын бүләкләү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Бердәм дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча 100 балл алган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларга һәм бердәм дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча 100 балл алган чыгарылыш сыйныф укучыларын әзерләгән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары педагогларына бер мәртәбә түләнә торган түләү билгеләү турында нигезләмәне раслау хакында» 2026 елның 15 апрелендәге 332 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктта «130 000 (йөз утыз мең)» сүзләрен «149 500 (йөз кырык тугыз мең биш йөз)» сүзләренә алмаштырырга».

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан

Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru халыкка җиткерергә.

Җитәкче Р.Ф.Хәкимуллин